| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

11.02.2026 40

**Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары Исемлеген раслау турында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 8.1 статьясындагы 10 нчы өлеше нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары Исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 17.10.2016 № 433 «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының аппараты һәм территориаль органнары вазыйфаи затлары Исемлеген раслау турында» боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Биредәге боерыкны исемлек нигезендә вазифаи затларга җиткерергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Н. Орлов

11.02.2026 ел. № 40
Татарстан Республикасы
гражданнар оборонасы
һәм гадәттән тыш хәлләр
Министрлыгы боерыгы
белән расланган

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының вазыйфаи затлары Исемлеге

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының (алда – Кодекс) 8.1 статьясындагы 10 нчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының (алда – Татарстан Республикасы ГТХМ) түбәндәге вазыйфаи затлары 2.21, 3.10 статьяларында каралган Административ хокук бозулар турында (вазыйфаи һәм юридик затларга карата) беркетмәләр төзергә хокуклы:

Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры, аның урынбасарлары;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы урынбасары;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең төп киңәшчесе;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең төп консультанты;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең I категория белгече;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлегенең 1 разряд өлкән белгече.